**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй , Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2019 елның 31 октябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй , Иске Арыш авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә, Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Керәшен Казысы авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Балыклы-Чүкәй авылы Шәкүровлар урамы юлы өчен;
- балалар уен мэйданчыгы алау
- кышкы чорда Балыклы-Чүкәй авылы җирлегендә юлларны карап торуга
- ял паркын эйлэндереп алу очен материаллар алуга
- Иске Арыш авылы Өчиле урамы юлына вак таш җәю һэм транспорт чыгымнары өчен
- Керәшен Казысы авылы зиратын әйләндереп алу өчен материаллар алуга;
- Керәшен Казысы авылы зиратына кадәрге юлга вак таш җәю һәм транспорт чыгымнары өчен

соравы (мәсьәләсе) буенча 2019 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 546 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенның 339 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 339 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй, Иске Арыш, Керәшен

Казысы авыл торак пунктларында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Балыклы-Чүкәй, Иске Арыш авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Балыклы-Чүкәй авылы Шәкүровлар урамы юлы өчен;
- балалар уен мэйданчыгы алау
- кышкы чорда Балыклы-Чүкәй авылы җирлегендә юлларны карап торуга
- ял паркын эйлэндереп алу очен материаллар алуга
- Иске Арыш авылы Өчиле урамы юлына вак таш җәю һэм транспорт чыгымнары өчен
- Керәшен Казысы авылы зиратын әйләндереп алу өчен материаллар алуга;
- Керәшен Казысы авылы зиратына кадәрге юлга вак таш җәю һэм транспорт чыгымнары өчен

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8нче йорт; Иске Арыш авылы,Үзәк урамы,23 В йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 11Б йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы: А.М.Нуретдинова